**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

18.02.2016 Яр Чаллы № 430

Тукай муниципаль районы инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең һәркем файдалана алырлык булуын бәяләү буенча чаралар планын («юл картасы») раслау турында һәм инвалидлар өчен объектларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең һәркем файдалана алырлык булуын бәяләү комиссиясен төзү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «федераль башкарма хакимият органнары, Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән эшчәнлек өлкәләрендә инвалидлар өчен хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеге күрсәткечләрен арттыру буенча чаралар эшләү тәртибе һәм сроклары турында» 17.06.2015 ел, № 599 карарын үтәү йөзеннән, шулай ук халыкның аз мобильле төркемнәренең социаль инфраструктура объектларына тоткарлыксыз керә алуын тәэмин итү максатында,

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы инвалидлар өчен объектларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең һәркем файдалана алырлык булуын бәяләү буенча чаралар планын («юл картасы») 1, 2, 3 кушымталар нигезендә расларга.
2. Инвалидлар өчен объектларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең һәркем файдалана алырлык булуын бәяләү комиссиясен 4 кушымта нигезендә расларга.
3. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Тукай муниципаль районы объектлары һәм хезмәт күрсәтүләренең инвалидлар өчен үтемлелек күрсәткечләре күрсәткечләрен арттыру буенча чаралар планын («юл картасы») раслау турында» 2015 елның 16 октябрендәге 3124 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
4. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») район газетасында бастырып чыгарырга һәм район сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.В. Асылгәрәев